**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 19 июнендәге 2559 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 3133 номерлы «Бертуган Петряевлар урамындагы җир кишәрлекләре өлешендә ачык сервитут билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалы – Казан электр челтәрләренең Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 3133 номерлы «Бертуган Петряевлар урамындагы җир кишәрлекләре өлешендә ачык сервитут билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 3133 номерлы «Бертуган Петряевлар урамындагы җир кишәрлекләре өлешендә ачык сервитут билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнары рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**